Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № Х-7**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 23 апреле

Балык Бистәсе муниципаль районының «Йолдыз» фонды Уставына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 123.20 маддәсе, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 29 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 69 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2009 елның 9 ноябрендәге XXXII-2 номерлы карары белән расланган «Йолдыз» фонды Уставына (Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2011 елның 30 мартындагы VI-4 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге унынчы абзацны өстәргә:

«-җирле үзидарә органнарының, оешмаларның, предприятиеләрнең, барлык милек рәвешләрендәге учреждениеләрнең административ биналарын төзүне һәм капиталь ремонтлауны оештыруда ярдәм күрсәтү.»;

1.2. түбәндәге эчтәлектәге 4.21.1 пунктны өстәргә:

«4.21.1. Башкарма директорның вакытлыча булмавы яисә үз бурычларын үтәү мөмкинлеге булмау чорында башкарма директор вазыйфаларын башкару Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары белән Фонд бухгалтерына йөкләнә.».

2. Балык Бистәсе муниципаль районының “Йолдыз” фонды Башкарма директорына Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10 нчы районара инспекциясендә Балык Бистәсе муниципаль районының “Йолдыз” фонды Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганда мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга вәкаләтләр бирергә.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев